# «ВолонТин» проекты

«ВолонТин» – Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында волонтерлык эшчәнлегенә багышланган проект.

**Проектның максаты:** театрда волонтерлыкны үстерү өчен шартлар тудыру, катнашучыларга үзләрен волонтер буларак күрсәтү мөмкинлеген бирү, чаралар оештырылганда волонтерларның ярдәм итүе, шәһәр мохитендә волонтерлык идеяләрен популярлаштыру.

**Катнашучылар:** мәктәп укучылары (14+), студентлар, өлкәннәр.

**Волонтерлар эшчәнлегенең бурычлары һәм юнәлешләре:**

– проектлар, зур чаралар, фестивальләр, конкурслар, хәйрия чаралары, театр акцияләре, лабораторияләрне оештыруда, анкеталар үткәрүдә ярдәм итү;

– театр хезмәткәрләренә ярдәм итү (аэропорт, вокзалдан театр кунакларын каршы алу, делегацияләрне озатып йөрү һ.б.).

**Бу проект ярдәмендә волонтерлар:**

– театр өлкәсендә эшләү тәҗрибәсен алачак;

– актерлар, театрның иҗат төркеме, административ-техник өлеше белән аралашачак.

Волонтер эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары кысаларында, аерым алганда волонтерлар һәм театрда волонтерлык эшчәнлеге турындагы нигезләмә кысаларында башкарыла.

**Тинчурин театры волонтерлары:**

– эшне башкару өчен кирәкле мәгълүмат, җиһаз алырга;

– үз идеяләрен тәкъдим итәргә, волонтерлык эшчәнлеге мәсьәләләре буенча фикер алышуда катнашырга;

– үз эшләрен башкару өчен кирәкле, өстәмә белемнәр алырга хокуклы.

**Волонтерлар:**

– үзләренә йөкләнгән эшне төгәл һәм намуслы башкарырга;

– волонтерлык эшчәнлеге принципларын белергә, хөрмәт итәргә һәм үтәргә;

– театрның волонтерлык эшчәнлеген башкару өчен бирелгән матди ресурсларын сакларга;

– театрның конфиденциаль мәгълүматын ачмаска тиеш.

**Театр:**

– волонтердан башкарылган эше өчен хисап алырга;

– хезмәткәрләргә һәм милеккә ихтирамлы мөнәсәбәтне таләп итәргә хокуклы.

**Театрның бурычлары:**

– хезмәтен башкару өчен волонтерга театр эшчәнлеге турында тиешле мәгълүмат бирү;

– билгеле бер волонтерлык эшен башкару өчен укулар уздыру.

**Теркәлү:**

Безнең театр волонтеры булу өчен, зинһар, әлеге форманы (https://forms.gle/h9BTcVr85coGgVjY8 ) тутырыгыз.

**Волонтерлар өчен бонуслар:**

- рәсми таныклыкка ия булу;
- махсус футболка алу;
- спектакльләргә һәм театр чараларына бушлай йөрү.

**Проектның кураторы:**

Эльгина Мөхәммәтдинова

**Элемтә өчен телефон:** +7 906 116-34-20.